СОВЕТ
СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 июль 2023 ел. Иске Тәрбит ав. № 13

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» 2013 елның 17 гыйнварындагы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» 2013 елның 17 гыйнварындагы 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 2.5 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы нигезендә җирле үзидарә органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау бүлеге тарафыннан яисә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;»;

кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 2.7. пункт белән тулыландырырга:

«2.7. Ришвәтчелеккә каршы тору максатларында билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләр һәм (яисә) коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычлар таралган, һәм аңа карата керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, һәм (яисә) чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләрне, һәм (яисә) коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү турында карар кабул ителгән затны эштән азат иткән (вәкаләтләре туктатылган) очракта, мондый тикшерү тәмамланганнан соң һәм коррупциячел хокук бозу кылган өчен аңа карата җәза куллану турында карар кабул ителгәнчегә кадәр, мондый тикшерүне башкару турында карар кабул иткән затка күрсәтелгән тикшерелә торган затны коррупциячел хокук бозуны кылган өчен җаваплылыкка тарту мөмкинлеге булмау турында доклад тапшырыла.

Ришвәтчелеккә каршы тору максатларында билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләр һәм (яисә) коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычлар таралган, һәм аңа карата керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, һәм (яисә) чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләрне, һәм (яисә)

коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү турында карар кабул ителгән затны эштән азат иткән (вәкаләтләре туктатылган) очракта, мондый тикшерүне гамәлгә ашыру барышында мондый тикшерүне башкару турында карар кабул иткән затка күрсәтелгән тикшерелә торган затка карата мондый тикшерүне төгәлләү мөмкинлеге булмау турында доклад тапшырыла.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Иске Тәрбит авыл җирлеге Башлыгы В.Г.Тимофеев

Совет Старотябердинского сельского поселения
Иске Тәрбит авыл җирлеге Советы
ИНН 1621000534
ОГРН 1021606761967